РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕНЫРТИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422063, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Большие Нырты, ул. М.Джалиля, 13а
тел. (84362) 45-2-32

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ НЫРТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422063, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Нырты авылы, М.Җәлил урамы, 13а йорт

тел. (84362) 45-2-32

e-mail: Bnir.Sab@tatar.ru


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

27.02.2019 №3

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәтләре өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибен раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 — ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләү буенча факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибен расларга (кушымта теркәлә).

2. Әлеге карар җирлекнең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерелергә тиеш: http://saby.tatarstan.ru/nirti җирлекнең мәгълүмати стендлары да бар.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җирлек башлыгы Р. З. Сәфәргалиев

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге
башкарма комитеты карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару хакында тертибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Олы Нырты авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләү чыгымнарының факттагы күрсәткечләрен бастырып чыгару тәртибе (алга таба — Тәртип) «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше, Олы Нырты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә эшләнде.

1.2 Тәртип Олы Нырты авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен белешмәләр тапшыру, раслау һәм рәсми бастырып чыгару процедурасын билгели (алга таба — мәгълүматлар).

## II. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында мәгълүмат тапшыру тәртибе һәм составы

2.1 Мәгълүматлар квартал саен җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең уртача саны, шул исәптән хисап чорында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырган Олы Нырты авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача саны турында, шулай ук хисап чорында хезмәт хакы исәпләмичә (акчалата эчтәлек) хезмәт өчен түләү чыгымнарын гамәлгә ашыруга фактта юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләре күләмен чагылдыралар.

2.2. Мәгълүматлар хисап чорыннан соң килүче айның 5 числосына кадәр әлеге тәртип кушымта нигезендә бирелә.

2.3 Олы Нырты авыл җирлеге башкарма комитеты әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә форма буенча мәгълүмат формалаштыра.

## III. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибе

3.1. Олы Нырты авыл җирлеге башкарма комитеты отчет чорыннан соң килүче айның соңгы числосыннан да соңга калмыйча Олы Нырты авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан мәгълүмат раслау турында карар проекты әзерләнә

3.2. Олы Нырты авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган хисаптан соң килүче икенче айның соңгы числосына кадәр мәгълүматлар Олы Нырты авыл җирлеге сайтында басылып чыгарга тиеш.

Бастырып чыгару тәртибенә кушымта

Олы Нырты авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләре
саны һәм аларның хезмәт хакы өчен факттагы чыгымнары
турында квартал саен мәгълүматлар

**Олы Нырты авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында мәгълүмат**
**артында____________20___ел**

хисап чоры (беренче квартал, ярты ел, тугыз ай, ел)

| хезмәткәрләр категориясе | Хисап чорында хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны. | Факттагы чыгымнар хезмәт өчен түләү<br>хисап чоры, мең сум |
|---|---|---|
| Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре | | |
| шул исәптән:<br>муниципаль<br>хезмәткәр | | |